ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.02.2025 с.Старое Дрожжаное № 45

**2025 елга Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслауга үзгәреш кертү турында**

Татарстан Республикасы Рәисенең 2025 елның 07 февралендәге 5600-МР номерлы 2025 елга Татарстан Республикасы мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында азык-төлек продуктларына чыгымнарны өстәмә индексацияләү турында карары нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 18 сентябрендәге 385 номерлы карары **(1 нче кушымта)** белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең норматив чыгымнарына, **5 пунктны** түбәндәге яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«5. Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында азык-төлек продуктларына норматив чыгымнары

| Мәктәпкәчә мәгариф оешмасының эш сәгатьләре саны | Азык-төлек продуктларына, көнгә/тәрбияләнүчегә чыгымнар нормативлары | | | |
|---|---|---|---|---|
| | гомумүстерү төркемнәре (шул исәптән төрле яшьтәге) | | санаторий төркемнәре | |
| | 2 яшьтән 3 яшькә кадәр | 3 елдан алып мәгариф мөнәсәбәтләре туктатылганга кадәр | 2 яшьтән 3 яшькә кадәр | 3 елдан алып мәгариф мөнәсәбәтләре туктатылганга кадәр |
| 3-4 | 33,88 | 42,65 | | |
| 5-6 | 81,28 | 102,39 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 7-12 | 135,49 | 170,64 | 175,78 | 234,39 |
| 24 | 169,34 | 210,66 | 219,73 | 289,36». |

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пункты белән расланган мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын үзгәртү нигезендә мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрен финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш һәм басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Р. Измайловка йөкләргә.

Башкарма комитеты
Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов